СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №117 (7446) | 1 октябрь, 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

Татарстан республикасы Югары Советының XI сессиясе эшен дәвам итә

Бүген беренче тапкыр Бөтендөнья өлкәннәр көне билгеләп үтелә

Өченче буын

Үтеп баручы, юл бир! Күрәсеңме үз гомерләрендә күпне күрергә һәм башкарырга өлгергән өченче буын вәкилләре киләләр.

Тормышта җиңелү әрнүен дә, җиңү шатлыгын да, очрашу куанычын да, югалту хәсрәтен дә аз татымаганнар алар. Сынауларның һәммәсен кичереп, ныклы рухларын, күңел көрлекләрен саклап кала алган өлкәннәр туган шәһәрләре урамыннан горурлык һәм вәкарьлек белән атлыйлар. Бу адымнар аларны бәйрәмгә генә түгел, икенче чорга, киләчәккә илтә сыман. Күкрәкләрен бизәгән һәр бүләк—үзе бер тарих, үзе бер кыю адым. Ә һәр адым—ул үз-үзеңне аямау, һәм без—яшьләр үзебезне аңа һәрчак сәләтлебез дип әйтә алмыйбыз.

Бу буын кешеләренең тәннәрендәге яралары санап бетерерлек түгел. Ә күңел яралары—тагы да күбрәк. Битарафлыгыбыз, җиңел акылыбыз, холыксызлыгыбыз белән аларны арттыра күрмәсәк иде...

Бу йөзләргә текәлебрәк карасагыз, йөрәгегезгә таныш күп чалымнарны күрә алырсыз. Сезнең әтиегез яки бабагызның күз карашы нәкъ аларныкы төсле үк акыллы, сабыр, сезнең әниегез яки әбиегезнең елмаюы да шундый ук йомшак, кичерүчән. Алар кичерә беләләр, безгә дә шуңа өйрәнәсе иде. Тирән картлыкка кадәр күңелнең, җанның чисталыгын саклыйсы иде.

Урамнан өлкәннәр килә. Безнең вөҗданыбыз, горурлыгыбыз, үткәнебез һәм киләчәгебез атлый. Акрын! Артык сүз белән бу мизгелләрнең тантанасын куркыта күрмәгез! Мондый мизгелләр еш кабатланмый һәм һәркем аның ихтыярына буйсынып, заман һәм яшәү мәгънәсен, кеше кадерен, аның бөеклеген тоеп, чиксез ләззәт ала белергә тиеш.

ЭШ ТӨГӘЛЛӘНДЕ

«КОНДЫРЧА» КОЛХОЗЫ. Бу көннәрдә хуҗалык чөгендерчеләренең кәефләре бик әйбәт: колхозда чөгендер алу, аны дәүләткә сату эше тулысынча төгәлләнде.

160 гектарлы басуда эш комплекслы алып барылды. Әнвәр Вәлиев һәм Әсгать Тәмаев җитәкчелегендәге механикалаштырылган звенолар көннең һәр сәгатен, һәр минутын эшкә җигәргә тырыштылар. Чөгендерне чистартудагы апайлар да бик өлгер, җитез булдылар. Инде чималны ташучыларга килсәк, колхоз аны тулысынча үз техникасы белән башкарып чыкты. КамАЗ шоферлары Фаил Рәхмәтуллин, Фәргать һәм Сәлих Вәлиевлар, ГАЗ-53 шоферлары Сәгыйть Тәмаев, Илдар Яһудин завод белән басу арасында һич тоткарлыксыз, бик җитез йөрделәр.

Х. РӘХМӘТУЛЛИН.

Һәммәсе тырышалар

«ҮРНӘК» КОЛХОЗЫ. 130 гектарлы чөгендер басуының соңгы гектарларында чөгендер казу төгәлләнде. БМ-6 яфрак урдыру комбайннарында Ринат Нәмаев, Рәис Әхмәтов, Рифкать Миңнегөлов, РКС-6 һәм КС-6 чөгендер алу комбайннарында Хәмит Хуҗиәхмәтов, Тәлгать Галимов, Марат Хәйдәрҗанов техниканың җитештерүчән эшен тәэмин иттеләр. Алынган чөгендерне кагатларга ташып торучылар Рифкать Әхмәтов, Касыйм Мөстәкыймов, Әнәс Сәләхов та хезмәтләрен намус белән үтәделәр. Хәзер төп эш чөгендерче апайлар һәм чималны тояп озатучылардан тора. Тояүдә эшләүче Рөстәм Мотыйгуллин да, шоферлар Рәис Гобәйдуллин, Нәгыйм Һадиев, Инис Хәйдәрҗанов та заводка чимал ташуны якын көннәрдә төгәлләүне максат итеп эшлиләр.

И. ШӘЙХИЕВ.

• Бәйрәм адреслары буйлап

Яңа бәйрәм—өлкәннәр көне һәр җирдә үзенчә кызыклы, үзенчә истә калырлык итеп оештырыла. Оешма-предприятиеләр, авыл Советлары бу көнне олыларга үзара аралашу, хатирәләр белән бүлешү шатлыгы бүләк итәргә дә, хәленнән килгәнчә ярдәм күрсәтергә, аларның күңелен күрергә дә тырышачаклар.

Өйдән—өйгә, йорттан—йортка

«Норлатнефть» НГДУсы. Коллективта эшләп лаеклы ялга чыккан 280 кеше исәпләнә. Алар коллектив килешү нигезендә бездән һәртөрле ярдәм алып торалар. Инде өлкәннәр көнендә алар өчен махсус азык-төлек пакеты әзерләнәчәк. Анда—үзебезнең ярдәмче хуҗалыкта үстерелгән ит, карабодай. Без бу пакетларны өлкәннәргә үзебез таратып чыгарга уйлыйбыз.

О. ЛИЗУНОВ,
профком рәисе.

Беренче тапкыр түгел

Район потребительләр җәмгыяте. Бездә хезмәт ветераннары белән очрашу, кичәләр үткәрү гадәте күптәннән яши. Инде алар өчен махсус бәйрәм көне билгеләнгән икән, без аны тагы да тантаналырак итеп үткәрергә тырышачакбыз.

Безнең системада ветераннар 500 ләп кешегә җыелалар, шуңлыктан бәйрәмне дә 2 көнгә бүлеп үткәрергә туры киләчәк.

1 октябрь көнне Иске Әлмәт кусты азык комбинаты ветераннары үзләрендә, районның шәһәр сәүдә работниклары «Колос» кафесында чәй табынына җыелачаклар. Икенче көнне кафе җәмәгать туклануы хезмәткәрләрен бәйрәмгә чакыра. Фома, Мамык РТПлары, әзерләүләр конторасы шулай ук үзләрендә табын әзерләячәкләр. «Тряхнем стариной» дип исемләнгән шаян конкурста алар күңеленә хуш килер.

Тагы шунысы да бар: бәйрәмнән ветераннар буш кул белән таралышмаячаклар. Аларның һәрберсенә 1 әр мең сум акчалата ярдәм һәм азык-төлек наборы тапшырылачак.

Т. ИЛЬЯЛОВА.

Чәе дә, бүләге дә

Район элемтә узелы. Безнең системада эшләп ялга чыккан 88 ветеран исәпләнә. Өлкәннәр көнен алар өчен чын бәйрәм рәвешендә үткәрергә җыенабыз. Иң элек, аларның һәрберсен әлеге бәйрәм белән котлап телеграммалар әзерләдек. Ветераннарга 400 сум күләмендә акчалата ярдәм күрсәтергә ниятлибез. Ә шәһәрдә яшәүче пенсионерларыбыз—алар 36 кеше исәпләнә—бу көнне чәй табыны артына җыелачаклар.

И. ЛЕТФУЛЛИНА.

Көзге Сабан туе

4 октябрьдә аэропорт мәйданында көзге «Сабантуй» бәйрәме үткәрелә. Бәйрәм тантанасы 9 сәгать 30 минутта ачыла. Аннан ярыш мәйданы аркылы атлар парады уза. Атлы спорт ярышлары 10 сәгатьтә башлана.

Бәйрәмнең программасы бай һәм кызыклы, җәйге сабантуйдан һич калыш түгел. Авызга йомыркалы кашык кабып, капчык киеп, көянтә белән су күтәреп йөгерү, аркан тартыш, капчык белән сугыш, авыш колгага йөгереп менү, әтәч алырга колгага күтәрелү, гер күтәрү буенча ярышлар тамашачыны үзенә җәлеп итәр, билгеле. Күз бәйләшле уеннарда—чүлмәк вату, уенчык кисү, капчык белән сугышуда катнашучылар аз булмас. Сөт имүдә ярышу да бәйрәмдә катнашучылар арасында кызыксыну уята торган бәйге.

Программаның үзәгендә традицион милли көрәш тора, әлбәттә. Бу бәйгедә шәһәр һәм авылның иң көчле егет, ирләре бил алышачак. Ул 12 сәгатьтә башлана.

7 сәгатьтән бәйрәм мәйданында азык-төлек һәм промышленность товарлары ярминкәсе башлана. Анда шәһәрнең сәүдә предприятиеләре белән беррәттән колхозлар һәм совхозлар да катнашачак. Программада халык соравы зур булган әйберләрне аукционда сату да каралган.

Мәдәният программасы 10 сәгатьтә башлана. Анда шәһәр һәм авылның үзешчән сәнгать көчләре, тынлы оркестр чыгыш ясый.

Моннан тыш, шәһәр стадионында мавыктыргыч спорт ярышлары уздыру планлаштырылды. Андагы бәйгеләр 10 сәгатьтә ачыла. Бер үк вакытта шәһәр паркында аттракционнар эшләп торачак.

Бәйрәмгә рәхим итегез, райондашлар һәм кунаклар!

ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ

Мәшәкать кимеми

Норлат-Октябрь җиләк-җимеш питомнигы.

Бу көннәрдә питомникта җәйге сезон кебек үк җанлылык хөкем сөрә. Эш шунда: хәзер биредә үсентеләр утырту бара. Питомник эшчеләре үз биләмәләрендә үстерелгән алмагач, карлыган, груша, кура җиләге, слива һәм башка агачлар үсентеләрен казып алып сатуга әзерлиләр. Үсентеләр Роза Алексеева, Галина Кадящева, Полина Акмуллина кебек тәҗрибәле эшчеләр кайгыртуы нәтиҗәсендә нык һәм өметле булып үсәләр. Аңа халыкта сорау да зур. Бүгенге көнгә питомник халыкка 18600 данә төрле сорттагы алмагач, 11 мең карлыган, 4 мең груша, 300 кара слива, 2400 чия, 2000 данә кура җиләге сатты инде.

Бу эш әле дә дәвам итә. Гомумән, питомник коллективына эш бер дә бетеп тормый. Аннан соң кышкы утау, аннан үсентеләрне ялгау һәм башка мәшәкатьләр тоташачак.

С. ФРОЛОВА.

Бу тормышның чияләнеп беткән төеннәрен чиште кулыгыз.

«Бирде дөнья кирәкне! Еламаска өйрәтте»...

Бу шигъри юлларны тормыш елларының авырлыгы битләренә буразналар булып яткан, чәчләренә чал булып ингән һәр кеше әйтә ала. Без аларны ветераннар дип атыйбыз һәм бу сүзнең тирәндәге мәгънәсенә игътибар да биреп тормыйбыз. Ә чынлыкта ветераннар—безнең өчен даими кирәкле ышаныч, өмет һәм мәхәббәт чишмәбез булып торалар.

Бүген мин үзем яхшы белгән, күп еллар бергә эшләгән һәм үземә авыр вакытларымда һәрчак таяныч тапкан кешем турында сөйләргә телим. Коммунела Владимировна Изотова.

Бу исем күпләр өчен бик тә таныш. Чөнки ул 15 елдан артык район мәдәният бүлеген җитәкләде. Һәм бу чорда районның бер генә почмагында да аны белмәгән бер генә кеше дә юк иде. Татар авылларында аны үз итеп «Наилә апа» дип йөрттеләр.

Коммунела Владимировна үз эшен яратып башкарды. Мәдәниятка кагылышлы һәр нәрсәне күңеленә якын ала иде ул. Ул эшләгән елларда районда күп кенә мәдәният объектлары төзелде. Район мәдәният йорты да шул еллар җимеше.

Бер үк вакытта яшьләр арасында мәдәниятка омтылучыларны эзләүдән дә тукталмады. Аларны уку йортларына урнаштыру турында кайгыртты һәм укыган елларында игътибарыннан калдырмады.

Бу елларда алынган бүләкләре күп аның. Әмма арада иң кадерлесе — Ана медале. Коммунела Владимировнаның балалары бишәү—дүрт улы һәм бер кызы бар. Инде оныклары, аларның да балалары бар хәзер. Гаилә зур, шуңа күрә мәшәкатьләре дә, шатлыклары да җитәрлек. Һәр онығына, оныкларының һәр баласына да җитә аның күңел җылысы.

Коммунела Владимировна күптән инде лаеклы ялда. Әмма аның бөтен яшәеше, җаны мәдәният белән бәйләнгән. Бернничә ел район мәдәният йорты каршындагы «Ветеран» клубына җитәкчелек итте, МСОның кызыл почмагында хуҗа булды. Күргәнегезчә, ял итәргә туры килгәне юк әле. Быел 1 сентябрьдә беренче мәктәпнең тынгысыз 8«А» классына килде, ничек яшәгәннәрен, нәрсәгә ышанганнарын, ни өчен көрәшкәннәрен сөйләде. Латыш укчысының оныгы, Себердә совхоз оештырган һәм туган җиреннән сөрелгәннәргә һәртөрле ярдәм күрсәткән гаҗәеп кешенең кызы Коммунела Владимировна үзенә бөтен кешелеклелек сыйфатларын җыйган шәхес. Бу сыйфатларның һәммәсен үз эченә алучы бер төшенчә бар: намуслы, вөҗданлы кеше диләр. Аның бүгенге көндә үзенең партбилетын һәм Почет Билгесе орденын кадерләп саклавы да шушы сыйфатның бер чагылышы.

Идеалларның бер селтәнүдә генә юкка чыкмавына аның иманы камил.

Үз буынына тигән сынауларның һәммәсен кичерде Коммунела Владимировна. Алар буыны үз чоры идеяләренең дөреслегенә изге бер ышану белән ышанып яшәде һәм эшләде. Шуңа күрә дә Ватаныбызда килеп туган вакыйгалар, үзгәрешләр барыннан да элек аларның йөрәкләренә килеп кагыла.

Өлкән буынга карата: дөрес эшләмәгәнсез, дөрес яшәмәгәнсез дип рәхимсез гаепләүләр ташлануы белән һич тә килешә алмый Коммунела Владимировна. Авыр, бик тә авыр аларга бүген. Көн итүе дә, гомер итүе дә авыр. Күңелгә кагылулары, могаен барыннан да авырррактыр.

«Шәфкатьлелек— ул мәңгелек төшенчә, ул — яктылык һәм шатлык чыганагы. Шәфкатьлелек күрсәтеп сез үзегезгә яңа көч алырсыз, җаныгызга тынгы һәм бәхет табарсыз. Сезнең әбиләрегезгә, бабаларыгызга һәм гомумән таныш булмаган өлкән кешеләргә күрсәткән шәфкатьлегегез аларның бу авыр чордагы яшәешен җиңеләйтер». Бу сүзләрне Коммунела Владимировна 1 нче мәктәпнең 8«А» класс укучыларына әйтте. Һәм нәкъ менә шәфкатьлелекнең дөньяны һәлакәттән коткарачагына, безнең һәркайсыбызның җанында ышаныч, өмет һәм мәхәббәт саклаячагына ышанып әйтте ул.

С. ЕФРЕМОВА.

✦

Аңардагы һәр нәрсә күңелгә ятышлы: йомшак тавышы да, ярымшаян формада сөйләшү алып бару рәвеше дә, киемендәге җыйнаклык та, мөнәсәбәтләрендәге таләпчәнлек тә. Ул бөтен яктан да матур, Чехов герое сыман. Кешеләргә чиксез мәхәббәт белән тулы җанлы, югары тәртипле интеллигент. Әйе, әйе, ул — тактлылыгы белән һәрчак һәм һәркемне сокландыручы Исаак Львович Сандлер.

Аның чит кайгыга беренчеләрдән булып эндәшүе, кирәк минутта ярдәмгә килүе беркайчан тыгызлаучан, артык булмый.

Исаак Львович белән аралашу һәрчак күңелле. Ул үзе белән күтәренкелек, оптимизм рухы алып килә һәм янәшәдәгеләр белән теләп бүлешә сыман. Василий Иванович Спасов белән дә аның сөйләшер сүзләре күп. Һәр икесе кан-яшь тулы сугышны узган, аннан бергә шәһәр мәктәбендә укыткан кешеләр. Аларның һәр икесе—без бүген бәйрәм иткән өлкән буын вәкилләре. Шуңа аларның зирәклеге һәм акылы, киң күңеллелеге һәм тормышка мәхәббәте алдында бүген түбәнчелек белән баш иябез.

● Бәйрәм адреслары буйлап

Фермерлар ярдәме

Киекле авылында икенче ел инде «Тегермән» фермер хуҗалыгы эшли. Илнур Мостафин җитәкләгән бу хуҗалык ак он тарттыру белән шөгыльләнә.

—Өлкән яшьтәгеләр көне уңаеннан авыл Советы территориясендәге ялгыз карт һәм карчыкларга 10 ар кг. бушлай ак он бирергә булдык,—ди хуҗалык әгъзасы Нәфис Нургатин.— Авыл Советы шундый 52 кешенең исемлеген төзеп бирде. Бериш халык онын алды инде.

Игелекле эш башкаралар фермерлар. Аларга рәхмәттән башка ни диясең тагын.

Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.

Үзен күптән үк күреп белсәм дә, аның белән танышлыгыбыз икебез дә мавыгып уйный торган шашка тактасы артында очрашулардан узмаган иде моңарчы. Ничә еллар үзара көч сынашырга насыйп булса да (ә аның кебек оста шашкачы белән уйнавы минем кебек урта кул уенчыларга гына түгел, шактый үк кәттә шашкачыларга да зур мәртәбә), Василий Павловичның гомер юлы, тормышы белән җентекләп кызыксынганым булмады. Шуңа күрә быел Җиңү көнендә шушы халәттә күргәч, бермәлгә аптырабрак та киттем. Ник дисәң, шашка тактасы артында (ул да үзенә күрә уен кыры бит инде) көндәшеңнең кем икәнлеге турында аның нинди шашкачы булуыннан чыгып кына фикер йөртәсең бит. Өлкәнме ул синнән, яшьме, үзең белән бер кордашмы, әллә, атаң-бабаң белән бер яшьлеме, анысы әһәмиятле түгел. Ник дигәндә, минем каршыга аны үзем чакырып утыртмаган ла, үзе килеп утырган бит. Ә менә шул көннән соң...

Яшерен-батырын түгел, җитмешне тутырган бу картның (гәрчә, кыяфәтенә, үз-үзен тотышына карап аңа һич тә бабай дип эндәшәсе килмәсә дә) җылы карашлы, көләч йөзен ерактан ук күрүгә, күңелдә үзеннән-үзе хөрмәт хисе уяна, һәм анысы бер аңа гына карата түгел, ә ул буын вәкилләренә һәм Василий Павлович белән бер иркенләп сөйләшеп утыру (ә анысы инде шашкадан башка булмаячагы көн кебек ачык иде) теләге борчып йөри иде. Дөрес, тормыш юлы, башыннан кичкәннәре, сугышта күргәннәре турында әллә ни ваклап сөйләргә яратмый торган булып чыкты ул. Хәер,

Идел буенда ачлыкн
иң котырган елында туг
малайның, Боек Ватан
гышының дәһшәтле ир
сен кадровый армия
фында каршылаган, анн
бер ел дигәндә кулы һ
аягы яраланып кайтк
егетнең, озак еллар тәр
җаваплы эшләрдә эшл
тә, ахыр чиктә инвал
лык буенча пенсиягә
тәргә мәҗбүр булган
нең балачак, үсмерчак һ
аннан соңгы гомер ха
рәләре, ачуым килмәг
бүгенге картлык көне
насыйп булган тормы
шартларында кабатланг
да бүтәнчә мөмкин дә
гелдер инде ул. Элек
нә бит ул картлар бе
үгет-нәсихәт бирәсе б
са «Сезгә рәхәт әле
менә без күргәнне күр
гез...» ди торганнар
бит. Кем әйтмешли, тыр
ша торгач анысы да б
ды: дөнья тигезләнде.
де болай булса безнең
ынга да картайгач он
ларга гыйбрәт итеп с
ләрлек хатирәләре
туплана бара.

Тик шулай да торм
шыннан зарланмый Ва
лий Павлович, чөнки а
мәгънәсезгә үткәрмә
ул. Сугыш кырында
ңелсә дә (хәер, ярала
дан беребез дә фәреш
канаты астында түге
тормыш кырын авырл
ларга карамастан нык
белән үткән. Һәм бәйр
җитсә, нәкъ менә сугыш
алган күпсанлы орд
медальләрен горурлан
тага, сугыштан соң
башкарган җаваплы
ләрнең илгә-көнгә фай
китергәнлеген яхшы бе
Шуңа күрә сугыш кыр
көрәшеп, тормыш кыр
тырышып үткән ветер
әле һаман да мавыг
якын күрә торган шаш
кырында көрәшкә дә
ныч күңел белән аль
һәм... җиңми калмый

РӘСЕМДӘ: сугыш һ
хезмәт ветераны В.
Краснов.

Еллар узгач, бар асылы белән бәяләнер гомер юлыгыз...

Вакыт болай да тынгысыз уза торды, ә ул аны һаман ашыктырды: тизрәк, тизрәк... Кая шулай ашыкты дисезме? Юк, узылган гомереннән баш тартмый ул һәм аны кабатларга туры килсә дә барысы да үзгәрешсез— элеккечә калыр иде. Аңа үзенең тумышыннан да, узган гомер юлыннан да оялырга урын юк. Кызганыч, бала чагы гына булмады. Аның бала чагын сугыш сызып атты. 12 яшендә олы ирләр эшен башкарырга туры килде. Аталар фронтка киткәч, нишлисең!

Әтисенең үлеме турында хәбәр килгәч әнисенең күз яшеннән шешенгән йөзен бүген дә ачык хәтерли ул. Марска ул вакытта ундүрт яшь иде һәм ул үзен чын ир-егет, гаиләнең терәге һәм яклаучысы итеп саный иде. Алар бу вакытта Михайловка поселогында яшәделәр. Эшчән халык җыелган иде анда. Әле утыз тугызынчы елда ук икмәк тапшырудагы уңышлары өчен хуҗалык премия буларак мотоцикл алды. Бу могҗизаны күрергә хәтта күрше районнардан да килделәр ул чакта.

17 яшендә бригадир камытын киеп (әтисенең вазифасын үз өстенә) алгач егет укырга кирәклеген аңлады. Менә ни өчен ул армиядән кайтуга ук белем алуын дәвам итте, ә бухгалтер булгач үзенең авылына кайтты.

Тиздән әкренләп хуҗалыкларны эреләндерү башланды. Мичурин исемендәге колхоз берләшкәч, көтмәгәндә аны рәис итеп сайладылар. Көтмәгәндә дию бик дөрес тә булып бетмәс, чөнки аның иңнәрендә бригадирлык йөге, армия хезмәте һәм 8 еллык бухгалтерлык эше иде инде.

Рәис постында аңа 28 ел эшләү насыйп булды. Беренче еллар иң авырлары булып истә калган. Тәҗрибә аз, җитмәсә ике сезон рәттән уңышсыз ел килде. Терлекләр күпләп үлде. Ач сыерлар җилдә дә чайкалып тордылар. Саламны (печән һәм фураж турында сүз дә юк) тракторлар белән Әлки районыннан ташыдылар. Ул елларны искә алуы да авыр. Әмма яшьлек дәрте, күңел күтәренкелеге, киләчәккә ышаныч үзен шулай сиздерә идеме, иң авыр вакытларда да: «Барысы да көйләнер»,—дигән өмет яшәде.

Кошчылык фермасын гына искә төшерик. Дәүләткә миллионлаган дәлә йомырка тапшыралар иде. Аны җәен дә, кышын да жигүле ат белән ташыды лар. Йомырка салган әрҗәләрне эшемәсен өчен кечкенә баланы төргәндәй төрәләр иде. Бу елларда Марс Ильич тормышында көлкеле хәлләр дә, күңел әрнеткечләре дә җитәрлек булды.

Үзе шаярта тагын: ярый әле рәис булып сайланганчы өйләнеп калдым, аңысына да вакыт табылмас иде, ди. Галинаны ул сайлау участогында, сайлаулар вакытында очрата. Комиссиядә бергә булалар. Шунда ук кызга тиздән өйләнәчәген,ә кәләшнең-- ул булачагын әйтә. Яшь китапханәче мондый «белдерүне» җитди сүз дип кабул итми. Әмма барысы да егет әйткәнчә була: авылда күңелле туй уза.

Галинаның тормышы мәшәкатьле була. Ирен көндезләрен районнан кешә-кара килгәндә генә күрә ул. Авылда кунакханә дә, ашханә дә булмый, төшкелеккә дә, кунарга да үзләренә чакырырга туры килә.
Ә өйдә, вакыты белән, бәрәңгедән башка берни булмаган чаклар да еш иде. Монда инде хуҗабикәнең осталыгына гына исәп тотарга кала.

Галина Ивановна ирен кызгана: гаиләсен дә, балаларын да күрми чаба. Көне-төне эштә. Бөтен гомеренә өч кенә тапкыр ял алды, анда да тиз арада чакыртып алдылар.

Курорт һәм санаторийлар турында ишетеп кенә белә. Югарыдагы башлыклардан да еш әләгә үзенә. Бик йөрәге әрнегәндә зарланып та куйганы бар:

—Бурычка алып дәүләт исәбенә яши белмим мин. Колхозның бурычлы булуын теләмим. Әгәр ничек эшләүгә карамастан теге яисә бу төзелеш өчен, яки әйбер, техника сатып алу өчен акча табылачагын белсәләр, кешеләр эштән бизәчәкләр бит. Мин аларга бу хәлне ничек аңлатыйм?

Авыр булды, вакыты белән аеруча авыр булды. Әмма авылдан китү уе аның башына килмәде.

Хәзер, пенсиягә чыккач Марс Ильич әйтерсең лә күптәннән килгән хыялын тормышка ашыра: хуҗалык белән шөгыльләнә, озаклап бакчада казына, инде менә умарта үрчетергә карар кылды. Бу дәвер кешеләре эшсез яши алмыйлар алар.Аларның ялы да—хезмәттә. Бәлки картаймауларының да сере шундадыр.

Г. ХӘЛИУЛЛИНА.

Бәхилләшү

(Чын хикәя)

—Су бирегезче, су...

Карчыкның тавышын ишетүче булмады. Ул, кипкән иреннәрен ялаштырып, күзләрен кәфендәй ак түшәмгә төбәде.

—Я ходаем, фани дөньяга кирәгем калмаганга күптән бит , инде, хәерле үлем генә бирсәңче...

Ул менә инде ничә ел таңны шул сүзләр белән аттыра. Юк шул, юк, ходай ишетми, күрәсең. Ишетсәме? Хәер, бу дөньяда алла бәндәсе Мәрбия карчыкның барлыгын ул да оныткандыр инде. Бар да онытты бит. Онытмаслык та түгел шул...

Карчык уйга чумды, озак хәрәкәтсез ятканнан соң аякларын кыймылдатып куйды. Әнә, палата ишеген кемдер ачты бугай. Уллары түгелме соң? Торырга, каршы чыгарга кирәк, болай яту килешмәс.

Әмма богау салгандай аякларны хәрәкәткә китерү җиңел түгел. Аннан керүче дә юк.Кем килсен инде? Ә бәлки... Килсәме? Мәрбия кечкенә чакларындагыдай аларның башларын күкрәгенә кысып, чәчләрен үбеп-үбеп назлар, сары бөдрәләрен күз яшенә чылатканчы елап, барысын да сөйләр иде.

Их, балалар! Сезнең күрше авылда үги ана кулында үсүегезне,буй җиткерүегезне, тормыш коруыгызны, инде оныкларүстерүегезне ишетеп тору җиңел булды дисезме соң? Ана бәгыренең телем-телем телгәләнүе, аның төннәрен сез яши торган авылның кыр капкасы төбендә җиргә тәгәрәп елап үткәрүе, иләсләнеп больницада ятып чыгуы, бөтен аңлы гомеренең ялгызлыкта үтүе...

Балалар каргышы төште бугай.

Әй ямьле язмыш!... Вәли белән яшьли кушылдылар алар. Дөресрәге, Мәрбияне аңа димләделәр. Яратмады ире аны. Беренче сәгатьтән, беренче көннән ук. Күнетер, ияләнер әле дип, бер-бер артлы ике малай тапты. Әмма Вәлинең күңеле үсмәде. Торабара түземлеге дә чыгырыннан чыкты.

—Аерам сине, теләсәң балаларны калдыр,—диде ул бер көнне. Ялынды Мәрбия, иренең аягына ятып елады. Әмма Вәли үз сүзендә нык торды.

Яшь хатын балаларның чүпрәк-чапракларын төргәккә төенләп, 2, 3 яшьлек улларын җитәкләп, туган авылына кайтып китте. Ике авыл арасы ерак бул-

(Ахыры 4 нче биттә).

Саннар һәм фактлар

Безнең шәһәрдә 4923 ветеран исәпләнә, аларның 180се яшьләре ягыннан бик өлкән буын кешеләре. Авылда яшәүче 7678 ветеранның 480е—шулай ук тирән картлыктагы кешеләр.

x x x

Быел 9014 ветеранга юл йөрү өчен 901400 сум компенсация түләнде.

✦

Хезмәт ветераннары. Гомер буе намуслы хезмәт куеп, ил алдында, халык каршында ихтирам яулаган өлкәннәрне шулай атау гадәте бар бездә. Аларга карата халыкта аерата җылылык, хөрмәт хисе яши, үзләре исә, инде лаеклы ялда булсалар да һаман кешеләргә файда китерергә тырышалар, тынгысыз җаннар. Мәсәлән, Якушкино авылыннан Ольга Ивановна Алякимова һәм Зинаида Николаевна Николаева кебек. Гомерләре буе колхозда төрле эштә эшләгән —терлек тә караган, салам да ташыган, икмәк тә чистарткан, чөгендер дә иккән бу апайлар пенсиягә чыккач та кул кушып өйдә утырырга ашыкмадылар. Әле узган ел да чөгендер дә иктеләр, ындыр табагында ашлык та

чистарттылар (фотограф аларны нәкъ шул эштә рәсемгә төшереп алган иде). Барыбер яшь үзенекен итә, быел апайлар даими эшкә чыга алмадылар. Әмма «Сезнең ярдәмегез кирәк, булышсагыз иде, апайлар» дип мөрәҗәгать итсәләр, ветераннар берсүзсез ярдәмгә күтәреләчәкләр,— моңа беркем шикләнми.

«Комбайн» колхозының Чурабатыр бригадасының сарыкчылык фермасында эшләүче Михаил Архипович Котов белән Иван Андреевич Краснов та (икенче рәсем) хезмәт финишларына якынайганда шул хакта еш сөйләшәләр. Аяк- кул йөргәндә, күз күргәндә нинди тик тору ди әле ул? Кеше арасында күңел дә үсә, эшләп кайтсаң ашау да үтә. Гомер барынча ходай эшләп яшәргә язсын.

Өлкәннәрнең күбесенә хас беркатлы да, шул ук вакытта гаҗәп зирәк тә философия шундый. Гомер барынча эшләргә омтылган, көч-куәтен кызганмыйча халыкка хезмәткә баглаган өлкәннәрнең көннәрдән бер көнне үзләре ярдәмгә, кайгыртуга мохтаҗ затларга әвереләселәре күңелне тетрәндерә.Әмма ул көн һәркемгә килә. Кичә генә җир җимертеп дөнья куган әби-бабайларның гаҗизләнгән, картлык дигән мәкер каршында чарасызлыгын кичерергә без янәшәдәгеләр булышырга тиешбез. Игътибар һәм кешелеклелек, түземлелек, сабырлык белән аларны аңларга тырышыйк.

Н. Азизов фотолары.

Бәхилләшү

(Чын хикәя)

(Дәвамы. Башы 3 биттә).

маса да, юл Мәрбиягә бик озын тоелды: күзләреннән яшь түгел, кан коелды. Бу ике баланы ничекләр итеп аякка бастырыр, кеше итәр, кем сыендырыр үзләрен?! Ичмасам, әти-әнисе дә гүр ияләре.

Төп йортта очрашу ул уйлаганнан да күңелсезрәк булды. Абзасы кара коелды, килен исә канәгатьсезлеген яшереп тә маташмады.

—Сиңа урын тапсак та, балаларың өчен бездә идән дә буш түгел, күрәсең... Ни эшлисең, ярым җимерек өйдә болардан башка да тугыз кеше җан асрый иде шул. Төнпәрен, чыннан да, идән дә буш булмый. Кая инде монда?... Тик кая барырга, кемгә сыенырга?

—Әти, әти-я ба-а-ам,...

Яңа гына теле ачылып килә торган Әдибе әтисен таптырыпмы-таптыра. Ә бәлки? Юк, юк...

Мескен башка нинди генә уйлар килмәс. Шулай да бер нәтиҗәгә килде:

«Балаларны аталарына илтеп торам. Үземә торырга урын булгач алып кайтырмын...»

Их, шунда ялгыш адым ясамаса да бит! Илдә чыпчык үлми диләр, бергә булсалар, кыенлыклар да тизрәк җиңелер иде. Юк шул, шайтан котыртты бугай.

Карчык ыңгырашып куйды.

Гамбәр акыллы булды шул. Вәлидән баласы булмагангадыр инде, үги балаларны үз итте: какмады, сукмады. Җае туры килгәндә, бары каты бәгырьле әнкәләре белән генә битәрләде. Һәрхәлдә, күршеләре Мәрбиягә шулай ирештерәләр иде хәбәрне. Үз почмагы булгач, балаларын алырга дип ничә тапкыр барды. Кая инде балаларны күрсәтү!

—Килмә дә, йөрмә дә, балаларын ташлаган кеше оятсыз ул,—дип, болай да әрнегән җанына тоз сала иде каенанасы. Әмма йөрәккә күрсәтмә биреп булмый шул. Кичке әңгер-меңгер җиткәч, кача-поса авылга килеп, бәрәңге бакчалары аша Вәлиләрнең түбән тәрәзәләреннән балаларын күрсә, авылына канат куйгандай очып кайта иде. Ә күрмәсә... ялгыз ананың яшь коюына ике авыл арасындагы юллар гына шаһит иде. Юкка гына кырыкның өске ягына китүенә күзе начарланмады шул. Гөбе кебек шешкән аякларын да шушы юлда йөргәндә өшеткән иде.

Гомер үтте, Мәрбия ни балаларын кайтара алмады, янә тормыш корырга да җөрьәт итмәде. Бу елларда күрелгән кайгы, түгелгән яшь... Үз-үзенә кул салырга уйлаган вакытлары да аз булмады. Тик балалар кайтырлар, алар мине кичерерләр дип туктала килде. Инде менә больницада ята. Караучысыз, ялгыз булганга, монда китерделәр үзен. Аяк кулларының сызлавы чамасыз, йөрәге менә-менә туктар сыман була да, янә дөп-дөп эшләп китә. Борылып ятарга хәле дә юк. Ярый әле, янәшәдә мәрхәмәтле җаннар бар, булышалар. Ә менә кичә Мәрбия өчен бик сөенечле вакыйга булды. Әхәтнең яңа гына институт тәмамлаган улы аның хәлен белергә килде. Әбине үзгәртеп куйдылармыни? Караватына торып утырды. Хәлсезләнгән куллары белән Әнәснең нәкъ әтисенекедәй сары чәчләрен сыйпады, аркасыннан какты. Ә күзләреннән ихтыярсыз яшь—шатлык яшьләре акты: менә бит бәхет, онык килгән, аның оныгы. Инде улын да күрсә, үлсә дә үкенече булмас иде.

Төн тыныч үтте.

—Карале, кара, ник бер ыңгырашсын.

Палатадагылар гаҗәпкә калдылар: больницага салганнан бирле бер генә төнен дә саташмый-ыңгырашмый үткәрми иде бит.

Мәрбия күңеле нидер сизенгәндәй уянды. Ниндидер эчке сиземләү белән ул карашын ишеккә төбәде.

—Әнә, сестра керде. Врач та хәлләрен белешеп чыкты. Чү, әнә, тагы ишекне шакыйлар түгелме?

—Мөмкинме?

Ишектә кичә килгән яшь егеткә ике тамчы судай охшаган сары чәчле ир-ат күренде. Ул бермәлгә тораташтай катты, күзләре белән нидер эзләде. Аннан кызу адымнар белән тәрәзә буендагы карават янына юнәлде. Карчыкның күз аллары караңгыланды: бигрәкләр дә таныш йөз, карашы тагын... Балаларча атылуы ук шул бит. Юктыр, булмастыр. Төш кенәдер бу.

—Әни!

Аның тавышы калтырады, тамак төбенә утырган төер чишелеп китеп, күзләреннән эре яшьләр бәреп чыкты.

—Әни, мин килдем.

Әй, нәрсә дип аптырады соң бу Мәрбия? Югыйсә очрашкач сөйләшәсе сүзләре әллә ничә ел буе мең кат күңеленнән кабатланган иде. Аңа иелгән газиз йөз, дымсу күзләр, зур ачылган иреннәр—барысы да шулкадәр якында гына бит. Их, кочаклыйсы, үбәсе иде. Тик... ни өчен бу куллар шулай авырая бара соң?

—Кичер, әни, мөмкин булса, кичер.

—Әхәт, балам, бәгалмам...

Карчыкның шадра бите буйлап яшь ага башлады, аз гына күтәрелгән хәлсез куллары Әхәтнең тез өстенә төште. Нәрсә, нәрсә бу? Өзелеп көткән минутлар җиткәч кенә бит... Шулчак еллар буе көткән бу мизгел җуела, артка күчә башлады. Әнә, әнә ул иренен тешләп елый-елый юлдан атлый имеш. Артында ике баласы...

—Югалтмыйсы иде балаларны...

Бу Мәрбия карчыкның соңгы сүзе иде.

Р. ИБРАҺИМОВА.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ

ПӘНҖЕШӘМБЕ
1 ОКТЯБРЬ
ТАТАРСТАН КАНАЛЫ

7.00—8.00 «Чулпан».
17.55 Телефильм.
18.30 «Бәйрәм» ансамбле.
19.00 Татарстан.
19.30 Әлли-бәлли-бәү.
19.40 ЮС сессиясендә.

ОСТАНКИНО КАНАЛЫ

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.50 Яңалыклар.
9.20 «Байлар да елый».
10.50 «Жалейка ни дип елый».
11.20 Безнең музыкаль клуб.
12.20 «Галиҗәнап адъютанты». 3 серия.
13.35 Фильм-балет.
13.55 «Узып баручы җәйчыңы». 2 серия.
15.25 Телемикст.
16.10 Уолт Дисней күрсәтә.
17.00 Тарих һәм кешеләр.
18.20 Казах музыкасы концерты.
19.05 «Байлар да елый».
18.50 Мультфильм.
19.50 Телефильм.
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.30 «Миллион» лотосы.
22.05 «Һәркем үзенеке турында».
22.20 «Яңарыш».
23.20 Телескоп.
00.00 Яңалыклар.
00.25 «Мәхәббәт формуласы». Нәфис фильм.

«РОССИЯ» КАНАЛЫ

20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.30 Эшлекле кешеләр вакыты.
8.50 Буш вакыт.
9.05 Док. фильм.
10.05 Футбол.
11.40 НАТОдан репортажлар.
12.10 «Яшәмәк көн күрмәк».
12.50 «Санта-Барбара». 77 серия.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.20 Россия Конституция суды залыннан.
16.00 Сигнал.
16.15 Мульти-пульти.
16.45 Пилигрим.
17.45 Там-там хәбәрләре.
20.30 «Санта-Барбара».
21.20 Махсус сәүдә хәбәрчесе.
21.30 «Әйләнеп кайт диюче ераклык...»
22.00 Тын йорт.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Спорт каруселе.
23.25 Конституцион суд залыннан.
23.55 РФ ЮС сессиясендә.
00.25 Тын йорт.

ҖОМГА
2 ОКТЯБРЬ
ТАТАРСТАН КАНАЛЫ

7.00—8.00 «Чулпан».
18.10 «Җомга көн кич белән».
19.00 Татарстан.
19.30 Әлли-бәлли-бәү.
19.40 ЮС сессиясендә.

ОСТАНКИНО КАНАЛЫ

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
6.20 Иртәнге гимнастика.
6.30 Иртә.
8.50 Мультфильм.
9.20 «Байлар да елый».
10.05 Сәяхәтчеләр клубы.
10.55 Мультфильм.
11.10 «...уналтыга кадәр һәм өлкәнрәкләргә».
12.20 «Галиҗәнап адъютанты». 4, 5 серияләр.
14.40 Мультфильм.
15.25 «Бридж».
15.50 Бизнес-класс.
16.05 Блокнот.
16.10 Уолт Дисней тәкъдим итә.
17.00 А. Майкапара уйный.
17.15 Телефильм.
18.25 А. Сокуров.
18.55 Мультфильм.
19.05 Кеше һәм закон.
19.35 «Кара чибәр маҗаралары». 12 серия.
20.00 Могҗизалар кыры.
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.40 «Ыштан». Нәфис фильм.
23.05 «Фаберже» дөньясы».
23.15 «Музобоз».
00.20 Авто-шоу.
00.35 «Әйе».
01.05 «МТВ».

«РОССИЯ» КАНАЛЫ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.30 Эшлекле кешеләр вакыты.
8.50 «Нота Бене» студиясе.
9.30 Буш вакыт.
9.45 М-трест.
10.00 Тын йорт.
11.55 «Виндзор шаяннары».
12.50 «Санта-Барбара». 78 серия.
13.40 Крестьян мәсьәләсе.
14.20 Россия Конституция суды залыннан.
16.00 Телебиржа.
16.30 «Кара барон турында бер сүз әйтегез».
16.45 Җыр кая китә...
17.15 «Барып-кайту тарихы».
17.45 Там-там хәбәрләре.
21.00 «Хроно»
21.30 «Күзәтче». Нәфис фильм.
23.20 Конституцион суд залыннан.
23.50 РФ ЮС сессиясендә.
00.20 Кичке салон.

ШИМБӘ
3 ОКТЯБРЬ
ТАТАРСТАН КАНАЛЫ

7.00—8.00 «Чулпан».
18.00 Мультфильм.
18.10 Эстрада концерты.
19.00 Татарстан.
19.30 Әлли-бәлли-бәү.
19.40 ЮС сессиясендә.

ОСТАНКИНО КАНАЛЫ

7.00, 15.00, 21.00 Яңалыклар.
7.20 Иртәнге гимнастика.
7.30 Эшлекле кешенең шимбә иртәсе.
8.30 Моторлар дөньясында.
9.00 Мультфильм.
9.20 Марафон-15.
9.45 Эльдорадо.
10.15 Сәхнәнең арткы ягында. Елмаеп.
10.35 Кеше институты.
11.05 Игътибар: 10 ычы.
11.25 Музыкаль киоск. яшьләр.
11.55 «Стиль».
12.25 Кайту.
13.20 Эш.
13.50 «Колыма. Бер трест тарихы». 1 фильм.
15.20 «Якты юл». Нәфис фильм.
17.35 Кызыл квадрат.
18.15 «Театр+ТВ».
19.20 «Висбаденга бару». Нәфис фильм.
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.40 Брейн-ринг.
22.30 Юмор антологиясе.
23.10 «Төнгә кадәр һәм төн узгач».

«РОССИЯ» КАНАЛЫ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.25 «Рух, җан, тән».
8.55 «Воробьев таулары».
9.20 Әгәр дә сезгә...
9.50 Ретро-шлягер
10.15 «Сергей Радонежский». 2 фильм.
11.00 «Плюс унбер» каналы.
13.00 Уңыш зигзагы.
13.15 Пилигрим.
14.20 «Һәм шунда мин юк идем». Нәфис фильм.
15.35 Көньяк Корея. Узганнан бүгенгә.
16.15 Россия энциклопедиясе.
16.55 Футбол.
21.00 Алтын өзәнге.
21.30 «Голливудка бару». Нәфис фильм.
23.20 Ассорти.
23.50 «А» программасы.
00.20 «Ад Либитум».
00.50 «Кара». 3 чыгарылыш.

ЯКШӘМБЕ
4 ОКТЯБРЬ
ТАТАРСТАН КАНАЛЫ

7.00—8.00 «Чулпан».
15.40 Балалар өчен концерт.
15.55 «Әйләнеш». Нәфис фильм.
17.30 «Бирнәсез кыз». Спектакль.

ОСТАНКИНО КАНАЛЫ

7.00 Рухи көч сәгате.
8.00 «Спортлото» тиражы.
8.15 Мультфильм.
8.30 Концерт.
9.00 Иртән иртүк.
9.30 «Сәхифәләр актарганда».
10.30 Иртәнге йолдыз.
11.20 «Пи» билгесе астында.
12.10 Театраль очрашулар.
13.10 Яшь буын сайлый.
14.00 Рәсем сәнгате метаморфозалары.
15.00 Яңалыклар.
15.20 Әңгәмә.
16.00 Сәяхәтчеләр клубы.
16.50 Кечкенә концерт.
17.00 Панорама.
17.40 Телелоция.
17.55 Уолт Дисней тәкъдим итә.
18.45 Яңалыклар.
19.00 Футбол.
20.00 «Йолдыз сугышлары». Нәфис фильм.
22.00 Йомгаклар.
22.45 Спорт уикэнды.
23.00 Матадор.
00.00 Яңалыклар.
00.25 «Видеодром».

«РОССИЯ» КАНАЛЫ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.20 Билгесез мәдәниятләр.
8.50 Киләсе ел безгә ни әзерли?
9.20 ТВ-ателье.
9.35 Теләсәгез, ышаныгыз...
10.05 Битлек-шоу.
10.35 Кызлар, малайлар, сезнең өчен.
10.45 Крестьян мәсьәләсе.
11.15 «Корольлектәге маҗара». 6 серия.
11.45 «Аты-баты».
12.15 Телеуен.
12.45 Дуслар йорты.
13.15 «1812 елгы давыл»
13.45 «Дораэмон». 4 серия.
14.20 Театраль сәхифәләр.
20.30 «Сары су асты көймәсе». «Талса».
22.35 Мультфильм.
23.20 Спорт каруселе.
23.30 Онытылмас көннәр.

БЕЛДЕРҮ

Кизләү—Норлат юлында «Москвич» автомобиленең арткы утыргычын табучы кешене бүләк көтә. Мөрәҗәгать итү өчен адрес: Норлат шәһәре, Декабристлар урамы, 75.

МӨХӘРРИР В. В. ИСХАКОВ.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат Октябрь типографиясе. Тираж 3751. Заказ 117.